**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 15 февраль № 100

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Казан шәһәрендә урнашкан федераль әһәмияттәге мәдәни мирас объектлары территорияләре чикләрен һәм алардан файдалану режимын раслау турында» 2011 ел, 21 декабрь, 1034 нче карары белән расланган Казан шәһәрендә урнашкан федераль әһәмияттәге мәдәни мирас объектлары территорияләреннән файдалану режимына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Казан шәһәрендә урнашкан федераль әһәмияттәге мәдәни мирас объектлары территорияләре чикләрен һәм алардан файдалану режимын раслау турында» 2011 ел, 21 декабрь, 1034 нче карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 31 декабрь, 1077 нче карары белән кертелгән үзгәрешне исәпкә алып) белән расланган Казан шәһәрендә урнашкан федераль әһәмияттәге мәдәни мирас объектлары территорияләреннән файдалану режимына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

түбәндәге эчтәлекле яңа унберенче абзац өстәргә:

«тарихи шәһәр төзелеше мохитен саклау, мемориаль һәм архитектура-ансамбль ягыннан кыйммәтле, югалган тарихи элементларны (биналар, төзелмәләр, корылмалар, кече архитектура формалары, киртәләр, капкалар) торгызу, аларны торгызу өчен кирәкле фәнни мәгълүматлар җитәрлек булганда.»;

түбәндәге эчтәлекле яңа унөченче абзац өстәргә:

«Казань шәһәре, Карл Маркс урамы, 17 йорт (зур бина) адресы буенча урнашкан «Адмиралтейск конторасы комплексы, XVIII г., архитекторы Кафтырев В.И.» федераль әһәмияттәге мәдәни мирас объекты территориясе чикләрендә җир кишәрлеген рөхсәт ителгән куллану төрләре: эшлекле идарә, кибетләр, банк һәм иминиятләү эшчәнлеге, җәмәгать туклануы, кунакханә хезмәте күрсәтү, күргәзмә-ярминкә эшчәнлеге.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков